

Гелнур Хасян кызы Арсланова туган 1930 елда Лəмберə районы Нəсəпə (Мельцапино) авылында. Анын яшьлек еллары Боек Ватан сугышы вакытына туры килде. Шул вакыт авылда бик зур авырлыклар иде. Ботен колхоз эшлəре дə, ойдəге эшлəр дə, балалар асрау да хатын-кыз, яшvсмер ыланнар, бабайлар һəм əбилəр кулында булды. Нəсəпə авылынын һəрбер оендə 5,6,7 бала vсеп килде шул елларда. Сугыш башлангач, тиз арада оланнар vз яшьлəреннəн зурайдылар, зурлар белəн хəллəреннəн килгəнне башкардылар. Алар бик тиз эшкə дə, тəртипкə дə, сабырлыкка да ойрəнделəр. Барысы белəн бергə, олкəн яшьтəге əби-бабаларын да карадылар. Авырлыкка тvзделəр, назланырга, кvз яше чыгарырга вакыт булмады аларга. Авылда мəктəп эшлəде, укытучылары да авылныкы иделəр, эш белəн бергə белемне дə алырга олгерделəр. Менə шулай vсте Гелнур Хасяновна Арсланова.       Авыр сугыш елларында 11 яшьлек кечкенə кыз фермада дунгызлар ашатты; эшлəде зур апалар белəн бергə, алардан калмыйча. Зур-зур чилəктəге азыкны кvтəргəндə коче дə житте, сабыр итте, кvзеннəн яшь чыкмады: vзенен эштə булдыклыгын олкəн апаларга кvрсəтергə телəде.
Авыл бик зур иде. Бер котvгə авылдагы сыерлар белəн сарыклар сыймаганга кvрə, икенче котvче алдылар. Шулай ике зур котv булды. Колхозда гына тvгел, ойдə дə эш бик кvп иде: тываркараны багу да, сыер саву да. Шулай ул 15 яшендə сыер саварга да ойрəнде. Дунгыз фермасын бетергəч, сыер савучы булып фермага эшкə кvчте. Колхозда бар эшне кулда эшлəделəр, сыерларны да кулда савдылар. Сыерларны vзе кул белəн сауган кеше генə Гелнур апаны кvнеле белəн анлар, чонки бер сыерна да саварга бик авыр, ə 12-15 сыерны саву яшvсмер балага ничек? Шул арада беренче тапкыр бозаулаганнары да бар! Алар жигелмəгəн ат кебек - тирəлəренə якын барырга куркыныч. Торлесе булды: сот белəн чилəклəр дə очты, vзенə дə элəгə иде. Савып бетергəч  сыерлар аяклары белəн чилəк эченə дə баса иделəр – шулай итеп яшь савучынын соте дə югалган, vзе дə суккаланган.



